КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 25 декабрь г.Казань № 1029

Татарстан Республикасы Россия Федерациясендә һәм чит илдә транспорт комплексы тармагында күргәзмәләрдә һәм башка чараларда катнашу, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә транспорт комплексы тармагында күргәзмәләр һәм бүтән чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау максатларында юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм юридик затларның Татарстан Республикасы Россия Федерациясендә һәм чит илдә транспорт комплексы тармагында күргәзмәләрдә һәм башка чараларда катнашу, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә транспорт комплексы тармагында күргәзмәләр һәм бүтән чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Россия Федерациясендә һәм чит илдә транспорт комплексы тармагында күргәзмәләрдә һәм башка чараларда катнашу, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә транспорт комплексы тармагында күргәзмәләр һәм бүтән чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау максатларында юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин